**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.12.2025 № 1518

«2026-2028 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын гамәлгә ашыру

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәтен һәм муниципаль хезмәтне үстерү «Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.11.2013 ел, № 910 карары, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасын расларга.
2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» муниципаль казна учреждениесенә «2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерү» муниципаль программасының җирле һәм республика бюджетлары акчалары исәбеннән үткәрелә торган чараларын финанслауны тәэмин итәргә.
3. 2026 елның 01 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2023-2025 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районында муниципаль хезмәтне үстерүнең муниципаль программасын раслау турында» 21.07.2023 № 735 карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Әлеге карар 2026 елның 01 гыйнварыннан үз көченә керә.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин